РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

СОВЕТ МИЧАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА

422055, Республика Татарстан,
Сабинский район,
Село Старый Мичан , ул. Школьная,
12
тел. (84362) 42-3-31

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ МИЧЭН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422055, Татарстан Республикасы,
Саба районы,
Иске Мичэн авылы, Мэктэп урамы,
12 йорт
тел. (84362) 42-3-31

e-mail: mich.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
03.02.2020 г.

КАРАР
№ 3

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге Советының 2017 елның 21 августында 16 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан яллаучы (эш бирүче) вәкиленең коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә бердәм башкарма орган буларак катнашу яисә аларның коллегиаль органнары составына керү өчен рөхсәт алу тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

«Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында " 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Мичән авыл җирлеге Советы к а р а р кылды:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге Советының 2017 елның 21 августында 16 номерлы карары белән кабул ителгән “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан яллаучы (эш бирүче) вәкиленең коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә бердәм башкарма орган буларак катнашу яисә аларның коллегиаль органнары составына керү өчен рөхсәт алу тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәреш кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 1 пунктында «бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативы, " сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/rus/michan адресы буенча һәм авыл җирлегендә урнашкан информацион стендларда урнаштырырга.

3.Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Карарның үтәлешен тикшерүне үз өстемә калдырам.

Мичән авыл
җирлеге башлыгы

А. Ә.Гәрәев